**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Азнакай шәһәре Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 49-16 «20» 06 2017 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-03 номерлы Федераль законның 37 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 49 һәм 50 статьялары нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Азнакай шәһәре Советы карар кабул итте:

1. Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итәргә һәм аны Татарстан Республикасы Азнакай шәһәр Советының 2005 елның 24 октябрендәге 7-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында Нигезләмә нигезендә үткәрергә.

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучылардан конкурска документлар 2017 елның 22 июненнән 2017 елның 11 июленә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул итәргә: Татарстан Республикасы, Азнакай шәһәре, Ленин урамы, 22 йорт, 8дән 17 сәгатькә кадәр, төшке аш 12дән 13 сәгатькә кадәр, шимбә һәм якшәмбедән тыш, көн саен тел.7-26-62, факс 7-24-28.

2. Конкурс комиссиясенә 2017 елның 13 июлендә 11.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында түбәндәге адрес буенча конкурс үткәрергә: Татарстан Республикасы, Азнакай шәһәре, Ленин урамы, 22 йорт, конкурс нәтиҗәләрен һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советына кандидатлар турында мәгълүмат бирергә.

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатураларны карау өчен 3 кешедән торган Конкурс комиссиясе составын кушымта нигезендә расларга.

4. Конкурс турындагы хәбәрне рәсми матбугат басмасында - «Маяк» газетасында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Рәис М.З.Шәйдуллин